**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.01.2019 № 31

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкын 2019-2021 елларга гадәттән тыш хәлләрдән яклау» муниципаль максатчан программасын раслау турында

«2014-2020 елларга Татарстан Республикасында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында куркынычсызлыкны тәэмин итү дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 2 ноябрендәге 837 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының янгыннардан һәм су объектларында халыкка табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән китерелгән социаль икътисадый һәм экологик зыянны минимальләштерү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау» муниципаль максатчан программасын (алга таба - Программа) расларга.
2. Нурлат муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУнә ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда, Нурлат муниципаль районы бюджетыннан әлеге максатларга җибәрелә торган мөмкинлекләрне исәпкә алып һәм акчалар чикләрендә Программа чараларын гамәлгә ашыруга акча бүлеп калдыруны тәкъдим итәргә.
3. Шәһәр һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары җитәкчеләренә, Нурлат муниципаль районы оешмалары җитәкчеләренә, хокук формасына карамастан, программа чараларын тиешле бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклар хисабына вакытында тәэмин итүне тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Л.Н. Маняпов

**«2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау» муниципаль программасы**

**Программаның Паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | “2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау” (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләүчеләр | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәләре, бүлекләре;<br><br>«ТР буенча 11 ФПС отряды» 125 ЯСБ федераль дәүләт казна учреждениесе;<br><br>Нурлат муниципаль районы « Гражданлык яклау идарәсе” МКУ директоры;<br><br>Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлегенең әйдәүче консультанты (Нурлат муниципаль районы буенча) |
| Программаның максаты | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының халыкны, территорияләрне һәм инфраструктура объектларын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклауны арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен киметү, Гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру |
| Программаның бурычлары | 1. Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә нәтиҗәлелеген арттыру<br>2. Нурлат муниципаль районында кризиска каршы идарә системасын үстерү<br>3. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау өлкәсендә халыкны әзерләү |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | 2019-2021 еллар. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары: | Программаны финанслауның гомуми күләме 5976,2 мең сум*тәшкил итә, шул исәптән:<br>(мең сум) |

| Финанслау чыганагы | Һәммәсе | 2019ел | 2020 ел | 2021 ел |
|---|---|---|---|---|
| Бюджет района | 5456,2 | 1759,0 | 1819,9 | 1877,3 |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>
<table>
<tr><td>Бюджеттан тыш чаралар (предприятиеләр, оешмалар һ.б.чаралары.)</td><td>520,0</td><td>140,0</td><td>180,0,0</td><td>200,0</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>5976,2</td><td>1899,0</td><td>1999,9</td><td>2077,3</td></tr>
</table>
Искәрмә: * финанслау күләме фаразланган характерда һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш
</td>
</tr>
<tr>
<td>Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән нәтиҗәләре (гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге индикаторлары)</td>
<td>Программаны гамәлгә ашыру түбәндәгеләрне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк:<br>гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен матди резерв булдыру;<br>муниципаль район халкының билгеләнгән категорияләрен тәэмин итү өчен индивидуаль саклану чаралары һәм медицина чаралары туплау;<br>идарә, элемтә, мәгълүмат бирү һәм хәбәр итү системаларының, шулай ук кисәтү һәм бетерү өчен билгеләнгән көчләрнең һәм чараларның әзерлеге;<br>муниципаль район территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын куллануга даими әзерлек хәлендә тоту;<br>гадәттән тыш хәлләр куркынычы һәм барлыкка килү турында халыкка хәбәр итү һәм җиткерү;<br>халыкка кирәкле ярдәм күрсәтү чараларының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында ашыгыч оператив хезмәтләрнең үз вакытында мәгълүмати хезмәттәшлеге;<br>тормыш эшчәнлеге иминлеге мәсьәләләре буенча халыкны әзерләүне камилләштерү;<br>гидротехник корылмалардан (буалардан) авариясез файдалану);<br>халыкны, барыннан да элек балаларны, әзерләү, йөзү һәм суда коткару кагыйдәләренә өйрәтү; су объектларында куркынычсызлык күнекмәләренә әзерләү</td>
</tr>
</table>

## I. Программаның чишелешенә юнәлдерелгән проблеманың характеристикасы

Программа гражданнарны табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау дәрәҗәсен һәм су объектларында кешеләр иминлеген арттыруга, Гражданнар оборонасы бурычларын үтәүгә, кешеләрне коткару, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне үтәүгә һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкка ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән. Климатны, хуҗалык эшчәнлеген глобаль үзгәртү процессында яки эре техноген аварияләр һәм һәлакәтләр нәтиҗәсендә барлыкка килә торган табигый һәм техноген гадәттән тыш хәлләр куркынычы Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкы һәм икътисад объектлары өчен шактый куркыныч тудыра.

Әлеге программа гадәттән тыш хәлләрне киметү өлкәсендә идарә итүне координацияләү механизмнарын үстерүгә, кризис һәм гадәттән тыш хәлләрдә ашыгыч ярдәм күрсәтү системасын оптимальләштерүгә, шулай ук заманча мәгълүмати-коммуникацион технологияләр һәм массакүләм мәгълүмат чараларының куллану нигезендә тормыш куркынычсызлыгы культурасын формалаштыру методларын һәм чараларын булдыруга юнәлдерелгән чараларны үз эченә ала.

Нурлат муниципаль районы территориясендә табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр туу куркынычы бар.

Табигый гадәттән тыш хәлләр куркыныч табигать күренешләре: язгы ташу, ташулар, көчле җилләр, кар яву, корылык, урман янгыннары нәтиҗәсендә килеп чыгарга мөмкин.

Техноген куркынычны потенциаль куркыныч объектлар тудыра.

Авария-коткару эшләре бу эшләрне башкара торган кешеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә куркыныч янаучы факторлар булу белән характерлана һәм махсус әзерлек, экипировка һәм җиһазландыруны таләп итә.

Район коткару хезмәтенең үсеш темпларын саклап калу һәм муниципаль коткару формированиеләренең эшләрен башкаруга әзерлеген арттыру өчен, авария-коткару көчләрен җиһазлау проблемаларын программа методлары белән хәл итәргә кирәк.

Гадәттән тыш хәлләрне бетерүнең нәтиҗәлелеге күп очракта матди ресурслар булу белән билгеләнә. Матди ресурсларның җитәрлек булуы гадәттән тыш хәлне минималь срокларда локальләштерергә, аның нәтиҗәләре масштабларын киметергә һәм төп бурычны хәл итәргә - зыян күрүчеләрне коткару һәм беренчел тормыш белән тәэмин итүне оештырырга мөмкинлек бирә.

Матди ресурслар номенклатурасы һәм резервларының күләме гадәттән тыш хәлләрнең фаразланган куркынычларыннан чыгып билгеләнә.

Әмма район территориясендә фаразланган гадәттән тыш хәлләр аркасында бу резервлар җитәрлек түгел. Матди ресурслар белән тәэмин итүнең тиешле проблемаларын региональ дәрәҗәдә хәл итәргә кирәк.

Зур масштаблы гадәттән тыш хәл килеп туган очракта куркыныч районнардан халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларына (алга таба - ВУП) эвакуацияләргә һәм зыян күрүчеләрнең беренче чиратта тормышын тәэмин итүне оештырырга кирәк булачак.

Эвакуация чараларын планлаштыру нәтиҗәсендә Татарстан Республикасы буенча гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләр бүлегенең әйдәп баручы консультанты гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны беренчел тормыш белән тәэмин итүне оештыруга әзерлекне арттыру буенча чаралар күрергә кирәк дип билгеләнде.

Зур масштаблы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күрүчеләрне тормыш белән тәэмин итү проблемаларын хәл итү өчен яңа карарлар кирәк.

Тиешле проблемаларны хәл итү, социаль өлкә объектларын җиһазлау буенча максатчан программа чаралары булып:

- көндәлек режимда-социаль файдалы максатлар өчен;

- гадәттән тыш хәл режимында-зыян күрүчеләрне беренчел тормыш белән тәэмин итү өчен максатчан программа чаралары булып тора.

Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклау проблемасыннан чыгып, муниципаль дәрәҗәдә программа методлары белән хәл итәргә кирәк.

Нурлат муниципаль районы буенча су объектларында кешеләр үлүнең төп сәбәпләре булып:

-бу максатлар өчен җиһазландырылган булмаган урыннарда кешеләр коену;

- сулыклар янында хәмер һәм наркотик исерек хәлдә коену яки ял итү;

- балаларның йөзә белмәве;

-балаларның әти-әниләре каравыннан башка су коенуы;

- суда кешеләр тормышын саклау кагыйдәләре белән билгеләнгән сулыкларда гап-гади куркынычсызлык нормаларын үтәмәү тора.

Халыкны гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм суда куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендә күрсәтелгән проблемаларны хәл итү өстенлекле чаралар билгеләү, аларны гамәлгә ашыруда эзлеклелек һәм бу дәрәҗә хакимиятне, предприятие һәм оешмаларны җәлеп итү, шулай ук халыкта куркынычсызлык культурасын формалаштыру буенча системалы эш алып баруны таләп итә.

## II. Программаның максатлары, бурычлары, сроклары (этаплары) һәм максатларгаа ирешү һәм мәсьәләләрне хәл итү күрсәткечләре (индикаторлары)

Программаның төп максаты:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының халыкны, территорияләрне һәм инфраструктура объектларын табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклауны арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен йомшарту, Гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү.

Программаның төп бурычлары:

1. Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә нәтиҗәлелеген арттыру;

2. Нурлат муниципаль районында кризиска каршы идарә системасын үстерү;

3. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау өлкәсендә халыкны әзерләү;

4. Нурлат муниципаль районында кешеләрнең су объектларында куркынычсызлыгын тәэмин итү.

Программа чаралары системасына түбәндәгеләр кертелгән:

- халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау чаралары;

- су объектларында кешеләрнең иминлеген арттыру чаралары;

- оештыру чаралары.

Шул ук вакытта кайбер чаралар вакыт дәвамында гамәлгә ашырылачак, ә кайбер чаралар этаплап гамәлгә ашырылырга тиеш.

Һәр елны финанслау күләме программаның узган елгы чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча төгәлләштереләчәк.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары турында җентекле мәгълүмат программада күрсәтелгән.

Программаны тормышка ашыру вакыты - 2019-2021 еллар.

## III. Программа чаралары системасы

Программаның куелган төп максатларына һәм бурычларына ирешү өчен 2019-2021 еллар чорында Программаның түбәндәге чараларын гамәлгә ашырырга кирәк:

муниципаль районда гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүгә финанс чаралары резервын формалаштыру һәм саклау;

муниципаль район халкының билгеләнгән категорияләрен тәэмин итү өчен индивидуаль саклану чаралары һәм медицина чаралары туплау;

гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын куллануга даими әзерлек хәлендә тоту;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының барлык дәрәҗәдәге иминлек паспортларын эшләү һәм корректировкалау;

республиканың Нурлат муниципаль районы нефть һәм нефть продуктларының төрле катламнарын агызуны кисәтү һәм бетерү буенча план эшләү;

гидротехник корылмаларның эксплуатацион ышанычлылыгын арттыру буенча чаралар;

гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында халыкка ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасын булдыру һәм карап тоту;

Нурлат муниципаль районының бердәм диспетчерлык хезмәте эшчәнлеге һәм үсеше;

Нурлат муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр өлкәсендә укыту-консультация пунктларын төзү, җиһазлау һәм аларның эшчәнлеген оештыру;

халыкны, барыннан да элек балаларны, суда йөзү һәм коткару кагыйдәләренә өйрәтү;

су объектларында кешеләр үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен үз эченә алган листовкалар, белешмәлекләр, плакатлар әзерләү һәм тарату.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Бюджет чыганаклары:

-җирле бюджет-халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау буенча муниципаль озак сроклы программалар чараларын, шул исәптән әлеге программа кысаларында Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар алу өчен каралган акчалар (конкрет суммалар күрсәтмичә мөмкин чыганак буларак фаразлана);

- предприятиеләр акчасы.

Программаны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү законнарда билгеләнгән тәртиптә федераль бюджет, республика бюджетыннан, шулай ук Нурлат муниципаль районы бюджеты акчаларыннан файдалануны күздә тота.

Программаны финанслауның гомуми күләме 5976,2 мең сум тәшкил итә. Программаны тормышка ашыруны ресурслар белән тәэмин итү прогноз характерда

һәм район бюджеты акчалары мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш.

Программаны финанслауның гомуми күләме 5976,2 мең сум тәшкил итә*, шул исәптән:

| Финанслау чыганагы | Всего | 2019 год | 2020 год | 2021 год |
|---|---|---|---|---|
| Район бюджеты | 5456,2 | 1759,0 | 1819,9 | 1877,3 |
| Бюджеттан тыш чаралар (предприятиеләр, оешмалар һ.б. чаралар) | 520,0 | 140,0 | 180,0,0 | 200,0 |
| Барлыгы | 5976,2 | 1899,0 | 1999,9 | 2077,3 |

Искәрмә:
* финанслау күләме фаразланган характерда һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш

## V. Программаны тормышка ашырудан социаль-икътисадый һәм экологик нәтиҗәләрне бәяләү

Программа социаль характерда, аның нәтиҗәлелегенең төп критерийлары булып Нурлат муниципаль районы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау тора.

Әлеге программаның максатлары нигезендә түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү һәм тәэмин итү күздә тотыла:

гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен матди резерв булдыру;

муниципаль район халкының билгеләнгән категорияләрен тәэмин итү өчен индивидуаль саклану чаралары һәм медицина чаралары туплау;

идарә, элемтә, мәгълүмат бирү һәм хәбәр итү системаларының, шулай ук кисәтү һәм бетерү өчен билгеләнгән көчләрнең һәм чараларның әзерлеге;

муниципаль район территориясендә гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын куллануга даими әзерлек хәлендә тоту;

гадәттән тыш хәлләр куркынычы һәм барлыкка килү турында халыкка хәбәр итү һәм хәбәр итү;

халыкка кирәкле ярдәм күрсәтү чараларының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында ашыгыч оператив хезмәтләрнең үз вакытында мәгълүмати хезмәттәшлеге;

мәдәният тормыш эшчәнлеге иминлеге мәсьәләләре буенча халыкны әзерләүне камилләштерү;

гидротехник корылмалардан (буалардан) аварияседз файдалану);

халыкны, барыннан да элек балаларны,  суда йөзү һәм коткару кагыйдәләрен өйрәтү;

су объектларында куркынычсызлык күнекмәләренә әзерләү.

“2019-2021 елларга Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы халкын һәм
территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау”
программасына кушымта

# “2019-2021 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкын һәм территорияләрен гадәттән тыш хәлләрдән саклау” программасы чараларының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм финанслаулары

| Тәртип саны | Чараның исеме | Башкаручылар | Гамәлгә ашыру вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлеге | Индикатор күрсәткечләре | | | финанслау чыганагы | Финанслау күләме, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | | 2019 год | 2020 год | 2021 год |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| **Максаты: Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы халкының, территорияләренең һәм инфраструктура объектларының табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклануын арттыру, аларның тискәре нәтиҗәләрен киметү, Гражданнар оборонасы өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру** | | | | | | | | | | | |
| **1 нче бурыч. Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өлкәсендә идарә нәтиҗәлелеген арттыру** | | | | | | | | | | | |
| 1.1. | Муниципаль районда гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүгә финанс чаралары резервын формалаштыру һәм саклау | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүгә резерв булдыру буенча чаралар, процентларны үтәү | 100 | 100 | 100 | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| 1.2. | Муниципаль район халкының билгеләнгән категорияләрен тәэмин итү өчен индивидуаль саклану чаралары һәм медицина чаралары туплау | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты оешмалар (килешү буенча) | 2019-2021 еллар | муниципаль берәмлектә, предприятиеләрдә һәм оешмаларда җыелган шәхси саклану чаралары һәм медицина саклану чаралары саны, данә | 200 | 220 | 240 | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| 1.3. | Гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларын куллануга даими әзерлек хәлендә тоту | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | саклагыч корылмаларны куллануга әзерлек дәрәҗәсе, проценты | 100 | 100 | 100 | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| | | оешмалар (килешү буенча) | 2019-2021 еллар | | | | | Бюджетнтан тыш чыганаклар | 140,0 | 180,0,0 | 200,0 |
| 1.4. | Татарстан Республикасы Нурлат | Нурлат муниципаль | 2019-2021 еллар | муниципаль районның | 100 | 100 | 100 | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек | агымдагы эшчәнлек | агымдагы эшчәнлек |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | муниципаль районының барлык дәрәҗәдәге иминлек паспортларын эшләү һәм корректировкалау | районы Башкарма комитеты | | куркынычсызлык паспортларын эшләү һәм төзәтмәләр кертү дәрәҗәсе, процент | | | | | кысаларында | кысаларында | кысаларында |
| 1.5. | Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының барлык дәрәҗәдәге нефть һәм нефть продуктларын агызуны кисәтү һәм бетерү буенча планнарны эшләү һәм корректировкалау | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | муниципаль районның нефть һәм нефть продуктларын су агызуны кисәтү һәм бетерү буенча планнарны эшләү һәм төзәтмәләр кертү дәрәҗәсе, процент | 100 | 100 | 100 | Бюджеттан тыш чыганаклар | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| 1.6. | Гидротехник корылмаларның эксплуатацион ышанычлылыгын арттыру буенча чаралар | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | гидротехник корылмаларны (буаларны) аварияcез эксплуатацияләү дәрәҗәсе, процент | 100 | 100 | 100 | муниципаль район бюджеты | 296,7 | 296,7 | 296,7 |
| | | | | | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| **2 нче бурыч. Нурлат муниципаль районында кризиска каршы идарә системасын үстерү** | | | | | | | | | | | |
| 2.1. | Гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычы турында халыкка ашыгыч хәбәр итүнең комплекслы системасын булдыру һәм карап тоту | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | башкарылган эшләр күләме, процент | 100 | 100 | 100 | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| 2.2. | Нурлат муниципаль районының бердәм диспетчерлык хезмәте эшчәлеге һәм үсеше | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | билгеләнгән бурычларны үтәүгә әзерлек дәрәҗәсе, процент | 100 | 100 | 100 | муниципаль район бюджеты | 1462,3 | 1523,2 | 1580,6 |
| **3 нче бурыч. Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрдә саклау өлкәсендә халыкны әзерләү** | | | | | | | | | | | |
| 3.1. | Нурлат муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр өлкәсендә укыту-консультация пунктларын төзү, җиһазлау һәм аларның эшчәнлеген оештыру | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | булдырылган укыту-консультация пунктларының әзерлек дәрәҗәсе, процентлары | 100 | 100 | 100 | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| **4 нче бурыч. Су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү** | | | | | | | | | | | |
| 4.1. | Халыкны, барыннан да элек, балаларны йөзү һәм суда коткару кагыйдәләренә өйрәтү | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | Балалар-яшүсмерләр спорт мәктәбендә йөзү буенча белем алучы балалар саны. | 160 | 180 | 200 | муниципаль район бюджеты | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| | | | | | | | | Бюджеттан тыш чыганаклар | агымдагы эшчәнлек | агымдагы эшчәнлек | агымдагы эшчәнлек |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | кысаларында | кысаларында | кысаларында |
| 4.2. | Су объектларында кешеләр үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен үз эченә алган листовкалар, белешмәлекләр,плакатлар әзерләү һәм тарату | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты | 2019-2021 еллар | башкарылган эшләр күләме, процент | 100 | 100 | 100 | | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында | агымдагы эшчәнлек кысаларында |
| Программа буенча барлыгы, шул исәптән акча: | | | | | | | | | **1899,0** | **1999,9** | **2077,3** |
| муниципаль район бюджеты | | | | | | | | | **1759** | **1819,9** | **1877,3** |
| бюджеттан тыш чыганаклардан | | | | | | | | | **140,0** | **180,0** | **200,0** |